# ЧИШМӘ БАШЫ




Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ»МБМББУ, июнь, 2025 ел № 8

***Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы***

***Газетаның сәхифәләре:***

1. ***Рәхим итегез, дуслар, Сабантуй бәйрәме бездә!***
2. ***Эх, ямьле дә шул табигать кочагында.***
3. ***Сәламәт тәндә – сәламәт акыл!***

**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Рима Галип кызы.**
**Мөхәррир урынбасары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**Тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.**

***РӘХИМ ИТЕГЕЗ, ДУСЛАР!***

***САБАНТУЙ БӘЙРӘМЕ БЕЗДӘ!***

Шушы көннәрдә бакчабызда шаулап-гөрләп, күңелләрне ымсындырып, йөрәкләрне җилкетеп, милли бәйрәмебез - Сабантуй бәйрәме узды.

Максатыбыз – сабыйларны бу матур бәйрәмнең йолалары белән якыннанрак таныштыру.

Иртәдән бакчабызда бәйрәм рухы чагылды. Матур итеп татарча милли моңлы көйләр тавышы ишетелеп торды. Балалар берсеннән-берсе узыша-узыша төрле уеннарда катнаштылар: капчык киеп тә сикерделәр, чүлмәк тә ваттылар, таяк та тарттылар, кашыкка йомырка куеп та йөгерделәр. Бердәмлектә көч икәнен аңлау өчен аркан да тартып карадылар. Күз бәйләп кисү ярышында исә бер бала да бүләксез калмады! Бәйрәмдә җыр җырлап, биеп күңелләрне тагын да күтәрдек.

Сабантуй бәйрәме балаларга бик ошады, күңелләренә шулкадәр хуш килде. Йөзләреннән елмаю, күзләрендә кызыксынучанлык утлары иде. Бәйрәм тәмамлангач, истәлеккә фотога да төштек.

Сабыйларыбызны Сабантуй бәйрәме, татарның гореф-гадәте белән таныштыруны балалар бакчасыннан башларга кирәк икәненә тагын бер кат инандык.














## *Ямьле дә шул табигать кочагында!*

Җәйге матур көннәрнең берсендә балалар белән табигатькә экскурсиягә бардык. Экскурсиянең максаты – экология, тормыш иминлеге дәресләрендә алган белемнәрне ныгыту, балаларның уйлау, фикерләү сәләтләрен үстерү, аларда игътибарлылык, күзәтүчәнлек сыйфатларын тәрбияләү.

Экскурсиягә чыгар алдыннан без табигатьтә үз -үзеңне тоту кагыйдәләрен искә төшереп алдык. Табигать кочагында, матур җәйге болында ял иткәндә балалар белән җәйге болынның матурлыгына сокландык, балалар үзләре белән алып килгән тәмле ризыклар белән сыйландык, хәрәкәтле уеннар уйнадык. Шул ук вакытта тагын бер кат экологиягә кагылышлы кагыйдәләрне искә төшердек.

***Истә тот, дустым!***

- *урманда йөргәндә агач ботакларын сындырма!*
- *яз көннәрендә каен агачларын яралама!*
- *урманнарны янгынннан сакла!*
- *коры, җилле көннәрдә урман аланында учак якма!*
- *кискән агачлар урынында яшь үсентеләр утырт!*
- *кош ояларын туздырма!*







## *Сәламәт тәндә – сәламәт акыл!*

Авылыбызның спорт мәйданчыгында уздырылган Сәламәтлек көне балалар белән әңгәмә, саф һавада хәрәкәтле уеннар уйнап, ярыш-эстафеталар рәвешендә оештырылды.

Бүгенге көнебезнең максаты – “Чисталык- сәламәтлек нигезе” икәнен балаларга төшендерү, аларны физик яктан чыныктыру, сәламәтлекләренә карата кызыксыну уяту, саулыкны кайгыртырга өйрәтү, чыдамлык, кыюлык сыйфатлары тәрбияләү. Балаларга сәламәт булу өчен спорт белән дус булырга, чисталыкны сакларга, дөрес тукланырга, витаминнарга бай ризыклар ашарга кирәклеге турында тагын бер кат аңлатылды. Бу көн саф һавада хәрәкәтле уеннар уйнап, ярышларда көч сынашып, балалар өчен тәрбияви яктан бик әһәмиятле көн булып истә калды.





